ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.05.2023 г.Лениногорск № 1315

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 30 декабрендәге 1234 номерлы карары белән расланган торакны торак урыны, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле торак дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законнарга ярашлы рәвештә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, прокуратураның 02.05.2023 №02-08-03-2023/Прдп351-23-20920049 протестын карап, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карар бирә:

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 30 декабрендәге 1234 номерлы карары белән расланган торакны торак урыны, торак урынны яшәү өчен яраксыз, күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле торак дип тану буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтелә:

мөрәҗәгать иткән гаризаны да кертеп, бинаны карауны үткәрмичә теркәү датасыннан алып 30 календарь көн дәвамында яисә дәүләт күзәтчелеге (контроль) органы бәяләмәсе, яисә торак урынга экспертиза ясау;

теркәлгән көннән алып 20 календарь көн дәвамында гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә зыян күргән һәм шул ук вакытта объектларның (торак биналарның)

жыелма исемлегенә кертелмәгән бинаны карау акты төзелгән очракта (4 нче кушымта).».

2.Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Административ регламентлар» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Хәйбрахманов И.Р
5-44-72